3. (美)列文森著，郑大华 任菁译．儒家中国及其现代命运[M]．北京：中国社会科学出版社2000

4. 路笃盛．儒家学说与中国现代化进程[M]．北京：中央社会主义学院学报第九期54页2001年9月

5. 赵建民．中国文化传统与日本的现代化——兼析日本现代化进程中儒家思想之影响[J]．东南文化，1991(z1):3-8.

6. Виноградов А.В. Китайская модель модернизации. Поиски новой идентичности. – М.: НОФМО, 2008. – 363 с.

**УДК 81'366**

**Ю. Хисияма**

*Токийский университет иностранных языков, г. Токио, Япония*

**Г.А. Набиуллина**

*Казанский федеральный университет, г. Казань, Россия*

# ПРОБЛЕМА ИЗМЕНЕНИЯ ПО КАТЕГОРИЯМ ПРИНАДЛЕЖНОСТИ СУБСТАНТИВИРОВАННЫХ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫХ В ТАТАРСКОМ И БАШКИРСКОМ ЯЗЫКАХ

***Аннотация.*** *В статье рассматриваются история изучения и особенности склонения аффиксов принадлежности субстантивированных прилагательных. Исходя из изученного материала, можно констатировать, что сопоставительное исследование форм принадлежности прилагательных в татарском и башкирском языках позволило выявить семантико-морфологические схожести ее проявления.*

***Ключевые слова:*** *татарский язык, башкирский язык, аффиксы принадлежности, имя прилагательное, субстантивированное прилагательное.*

**Y. Hishiyama**

*Tokyo University of Foreign Studies, Tokyo, Japan*

**G.A. Nabiullina**

*Kazan Federal University, Kazan, Russia*

# THE DECLENSION OF POSSESSIVE AFFIXES TO SUBSTANTIVIZED ADJECTIVES IN THE TATAR AND BASHKIR LANGUAGES

***Abstract.*** *The article deals with the history of studying and the features of the declension of possessive affixes to substantivized adjectives. Proceeding from the material studied, it can be stated that a comparative study of the forms of adjectives in the Tatar and Bashkir languages allowed us to identify the semantico-morphological similarities of its manifestation.*

***Key words:*** *Tatar language, Bashkir language, affixes of affiliation, adjective, substantivized adjective.*

# ТАТАР ҺӘМ БАШКОРТ ТЕЛЛӘРЕНДӘ ИСЕМЛӘШКӘН СЫЙФАТЛАРНЫҢ ТАРТЫМ БЕЛӘН ТӨРЛӘНҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Тартым категориясе — татар теле һәм гомумән төрки телләргә хас булган үзенчәлекле грамматик категория. Бу категория предметның нинди дә булса затка караганлыгын белдерә. Төрки тел белемендә I һәм II зат тартым формалары, кагыйдә буларак, өч типка бүленә дип аңлатыла: Беренчесе – тартым кушымчалары ярдәмендә генә (синтетик ысул); дәфтәр-ем, дәфтәр-ең, дәфтәр-ебез, дәфтәр-егез.* Икенчесе – иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартымсыз исем белән (аналитик ысул); *минем дәфтәр, синең дәфтәр, безнең дәфтәр, сезнең дәфтәр.* Өченчесе – иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем белән (аналитик-синтетик ысул); *минем дәфтәр-ем, синең*

*дәфтәр-ең, безнең дәфтәр-ебез, сезнең дәфтәр-егез.* III зат формасы, I һәм II затныкыннан аермалы буларак, ике генә ысул белән билгеләнә: тартым *кушымчалары ярдәмендә генә (синтетик ысул);* аның дәфтәре. Иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем белән (аналитик-синтетик ысул); дәфтәре.

Татар тел белемендә, сыйфат сүз төркеменең, исемләшкәндә, тартым кушымчаларын кабул итүенә беренчеләрдән булып Г.Алпаров һәм соңрак В.Хангилдин, Д.Тумашева һ.б. игътибар иткәннәр. В.Н.Хангилдин, сан белән бергә, сыйфатның, исемләшеп, килеш һәм тартым кушымчаларын кабул итүе турында искәрмәдә генә яза. Автор фикеренчә, "сыйфат һәм санны аерым сүз төркеме буларак характерлаганда, тартым һәм килеш белән төрләнеш аларны төсмерләргә хезмәт итмиләр". Галим, аларны исемләшкән сүзләр дип карау белән чикләнгән, сыйфатның тартым кушымчасын алуы турында җентекле итеп тасвирламаган [6].

З.М.Вәлиуллина, *К.З.Зиннәтуллина, М.А.Сәгыйтов*, сыйфатның төп билгеләреннән башка сыйфатка хас булган тагын ике билгенең берсе итеп, сыйфатның исемләшүен күрсәтеп, III зат тартым белән төрләнгән үрнәкне бирә. Аларның фикеренчә, "Кайбер очракларда сыйфат, сыйфатланмыштан (исемнән) башка килеп, исем мәгънәсендә кулланыла, килеш, тартым белән төрләнә, берлектә һәм күплектә килә, ягъни сыйфат исемләшә" [1, с. 62].

Д.Г.Тумашева исә, сыйфатның исемләшү үзенчәлекләренә шактый җентекле аңлатма бирә. Ул, сыйфатланмыштан башка килгән сыйфатларның җиңел исемләшүләре, һәм сыйфатланмышның грамматик категорияләрен үзләренә кабул итеп, килеш, тартым, сан белән төрләнүләрен аңлату белән генә чикләнмәгән, исем кебек кулланылган сыйфатларның өч төре: исем-сыйфат мәгънәсе аерылып җитмәгән сүз, исемләшкән сыйфат, һәм сыйфаттан барлыкка килгән исем бар икәнен "кара" сүзе мисалында аңлата, шулай итеп ул исем белән сыйфат мөнәсәбәтенең катлаулы икәнен күрсәтә [5, с. 62-64].

"Татар грамматикасы" хезмәтендә сыйфат, субстанцияләнгәндә, исем үзенчәлекләрен алып, килеш, тартым белән төрләнә, берлектә һәм күплектә килә, исемнең синтаксик функцияләрен үти, дип язылган, III зат тартым белән *төрләнгән үрнәк бирелә*: *Әйбернең **яңасы** яхшы, дусның **искесе** яхшы* (мәкаль) [4, с. 67].

Ф.М.Хисамова, сыйфатларның сыйфатланмышларыннан башка килеп исемләшүләрен, һәм бу очракта аларның нәкъ исемнәр кебек төрләнә башлауларын "контекстта исемләшү" дип атап, күбрәк контекстка игътибар итә [8, с. 115]. Автор, *күлмәкнең яңасы, алманың кызылы, кызларның матуры* мисалларын биреп, сыйфатның үзе ачыклаган сүздән (гадәттә, иялек килешендә була һәм сыйфаттан алда килә) ераклашып, исемнәр кебек, килеш, тартым белән төрләнеп килә алуын исемләшкән сыйфатның үзенчәлекле кулланылышы итеп күрсәтә. Мондый төзелештә сыйфат ачыклаган исем күрсәтелмәскә дә мөмкин булуына, шул исем контексттан аңлашылуына да игътибар ителә [8, с. 115-116].

Ч.М.Харисова, сыйфатларның исемләшүе турында "сыйфатланмыштан башка килгәндә яки сыйфат белән сыйфатланмышның урыннары алышынганда, сыйфатлар исем шикелле килеш һәм тартым белән төрләнә, берлек яки күплек санда килә" дип яза, III зат берлек сандагы тартым белән төрләнгән мисалны да бирә: *Китапның **калынрагы** укучыларның күңеленә хуш килде.* [7, с. 35].

Башкорт тел белемендә, сыйфат сүз төркеменең тартым белән төрләнүенә азрак игътибар ителә. "Грамматика современного башкирского литературного языка" хезмәтендә, башкорт телендә сыйфатлар сыйфатланмышсыз кулланылганда субстанцияләнеп, сан, килеш, тартым кушымчаларын кабул итеп, ия функциясендә килә дип аңлатылса да, тартым белән төрләнгән мисаллар китерелмәгән [2, с. 170].

М.В.Зәйнуллин, исемләшкән сыйфатлар турында аңлаткан өлештә, III зат тартым кушымчаларын алган үрнәкләрне китерсә дә, сыйфат сүз төркеменең тартым белән төрләнү үзенчәлегенә аерым аңлатма бирмәгән: ***Бәләкәйеррәге** бигерәк үткер булып сыкты.* ("Агиҙел") *Ямғыр йыуа япраҡтарҙың **һарыларын**, **йәшелдәрен**.* (М.Кәрим) ***Олоһо** күрмәй, **бәләкәйе** белмәй.* (мәкаль) [3, с. 50, 51].

Шулай итеп татар һәм башкорт тел белемендә галимнәр, сыйфатның, исемләшеп, тартым белән төрләнүенә игътибар иткәннәр. Шулай да, исемләшкән сыйфатларның I һәм II зат тартым белән төрләнгән үрнәкләрен биргән һәм шуның үзенчәлекләрен аңлаткан фәнни хезмәтләр, тикшеренүләр табылмады.

Җыелган үрнәкләрдән күренгәнчә, татар һәм башкорт телләрендә исемләшкән сыйфатлар I һәм II зат тартым белән дә төрләнә. Мәсәлән: *Арада иң **акыллыбыз*** (Аманулла). *Әллә мин иң **матурыгыз** түгелме?* (әкият). *Атаң-әсәң, һөйгән **сибәрең*** (М.Кәрим). I зат берлек тартым кушымчаларын алган кайбер сыйфатлар эмоциональлек төсмерләре арттырылган эндәшү сүзләре буларак шактый еш кулланыла: *Тукта әле, **матурым**, тукта* (Т.Галиуллин). *Әсәйем, **көҙәрлем** һин минең!* (Р.Янбулатова).

Төрле сүзләргә *-дагы, -рак, дай, -лы/-сыз* (баш. *-даҕы, -ырак, -дай, -лы/-һыҙ*) кушымчалары ялганып ясалган сыйфатлар да, исемләшкәндә, *тартым кушымчаларын кабул итәргә мөмкин*: ***Өйдәгеләрең** нәрсә диде?* (вакытлы матбугат). *Ата-әсәнән төрлө әйбер таптырыу, **кыйбатырагын** алдыртырға тырышыу осраҕы аҙмы ни?* (вакытлы матбугат). *Егетләрнең **синдәйләрен** эзлим* (җыр).

Тартым формаларына килгәндә, сыйфат сүз төркемендә синтетик форма иң актив кулланыла. Бик күп булмаса да, аналитик-синтетик форма да кулланыла: *Син **минем кадерлем** булырсың, җаным* (К.Тинчурин). ***Беҙҙең матурҙарыбыҙ**, беҙҙең батырҙарыбыҙ* (вакытлы матбугат). I һәм II затта аналитик форма бөтенләй кулланылмый.

Тикшеренүләребезгә нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: *зат алмашлыгы яки предмет кирәкмәгән шартларда синтетик форма кулланыла. Зат алмашлыгы яки предмет кирәкле шартларда аналитик-синтетик форма кулланыла, I һәм II затта аналитик форма, ягъни тартым кушымчалары кыскартылган форма исем тибындагы сүзләрдә кулланылса, исемләшкән сыйфат тибындагы сүзләрдә мөмкин түгел. Аналитик форманың исемләшкән сыйфатларда кулланылмау сәбәбен тартым кушымчаларының кирәге зурмы-юкмы икәнлеге белән аңлатып була.*

**Әдәбият**


1. Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан: КДПИ, 1972. – 206 б.
2. Грамматика современного башкирского литературного языка. – М.: Наука, 1981. – 495 с.
3. Зәйнуллин М.В. Хәҙерге башҡорт әҙәби теле: морфология. — Өфө: БДУ, 2002. — 388 б.
4. Татар грамматикасы. Т.II. Морфология. – Казан: Татарстан фәннәр академиясе, 2002. – 448 б.
5. Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле: Морфология. – Казан: Тат.кит. нәшр., 1978. – 221 б.
6. Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. – Казан: Тат. кит.нәшр., 1959. – 642 б.
7. Харисова Ч.М. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясеннән лекцияләр. – Казан: Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, 2010. – 128 б.
8. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф нәшрияты, 2006. – 335 б.



**УДК 811.581**



**Ли Чжэньвень**

*Хунаньский педагогический университет, Чанша, Китай*
*Институт Конфуция, Казанский федеральный университет, г. Казань, Россия*


# ИССЛЕДОВАНИЕ СЕМАНТИКИ ОДНОСЛОЖНЫХ ИМЕН ПРИЛАГАТЕЛЬНЫХ, ОБОЗНАЧАЮЩИХ ТЕМПЕРАТУРУ В СОВРЕМЕННОМ КИТАЙСКОМ ЯЗЫКЕ


***Аннотация.*** *В этой статье рассматриваются прилагательные со значением температура, которые имеют как основные (прямые), так и переносные значения. Данная статья классифицирует односложные прилагательные, обозначающие температуру в современном Китайском языке, такие как «жаркий», «горячий», «теплый», «комфортный», «холодный» на две категории, теплая категория и холодная категория. В статье дается анализ основных и переносных значений прилагательных, обозначающих температуру, в обеих категориях соответственно, выявлено, что понимание данных прилагательных зависит от теории человеческого фактора.*



***Ключевые слова:*** *основные (прямые) значения, переносные значения, теории человеческого фактора.*



**Li Zhengwen**

*Hunan Normal University, Changsha, China*
*Confucius Institute in Kazan Federal University, Kazan, Russia*


# THE STUDY OF SEMANTICS OF ONE-SYLLABLE ADJECTIVES OF TEMPERATURE IN MODERN CHINESE


***Abstract.*** *Adjectives of temperature have their basic meanings and figurative meanings as well. This article classifies one-syllable adjectives of temperature in contemporary Chinese such as “scorching” “hot” “warm” “cozy” “cool” “cold” into two categories, the warm category and the cold category. It analyzes the basic meanings and the figurative meanings of temperature adjectives of both categories respectively, stating that the understanding of temperature adjectives depends on Human Centered Theory.*



***Key words***: *basic meaning, figurative meanings, Human Centered Theory.*